# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлеге составына керүче Түбән Ушма торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 4 «16» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең Түбән Ушма торак пунктында 2020 елның «16» ноябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Түбән Ушма буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

Түбән Ушма авылында вак таш җәелгән юлны ремонтлау (сатып алу, таш ташу)
-Түбән Ушма авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту
-Түбән Ушма т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Түбән Ушма авылында су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләү
-Түбән Ушма авылында балалар уен мәйданчыгы сатып алу , урнаштыру
.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 727 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 516 кеше, 70,9% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 516 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең Түбән Ушма дөрес, дип таныргa.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең Түбән Ушма торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлеге Түбән Ушма булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Ушма авылында вак таш җәелгән юлны ремонтлау (сатып алу, таш ташу)
-Түбән Ушма авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту
-Түбән Ушма т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Түбән Ушма авылында су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләү
-Түбән Ушма авылында балалар уен мәйданчыгы сатып алу , урнаштыру

3. Әлеге Түбән Ушма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушма авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.М. Ганиев.